| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН УРЫСБАГА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05 апреля 2024ел.**

Түбән
Урысбага

**КАРАР**
**№4**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның «12» июлендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлегендә адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, муниципаль берәмлек уставына ярашлы Түбән Урысбага авыл җирлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы, Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 1.5 пунктка Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл башкарма комитетының 2022 елның «12» июлендәге 11 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.5 пунктка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. алтынчы һәм җиденче абзацларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«адреслы барлыкка китерүче элементлар - ил, Россия Федерациясе субъекты, федераль территория, муниципаль берәмлек, торак пункт, урам-юл челтәре элементы, планлаштыру структурасы элементы һәм адреслау объектының идентификация элементы (элементлары);

адреслау объектының идентификация элементлары - җир участокларының номерлары, адресациянең башка объектларының типлары һәм номерлары;»;

1.2. Тугызынчы һәм унынчы абзацларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«планлаштыру структурасы элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнар тарафыннан бакчачылык яисә үз ихтыяҗлары өчен яшелчәчелек алып бару территориясе; урам-юл челтәре элементы - урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында .http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

Түбән Урысбага
авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Сибгатуллин.